ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 апрель 2017 ел № 2234

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль ярдәм күрсәтү хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М :

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 номерлы карары редакциясендә) белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына, 7 бүлектәге III кисәкнең 7 пунктындагы «Башкаручылар» графасында «шәһәр Башкарма комитеты» сүзләрен «Башкарма комитетның районнар Хакимияте» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин